ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2021 елның 22 гыйнвары** **Чистай шәһәре** **№ 23**

2021 елга салым салынырга тиешле гражданнар кеременең һәм мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 49,51 статьялары, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм әлеге законга кушымтада бәян ителергә тиешле мөлкәт хакын билгеләү методикасы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Россия Федерациясе субъектлары буенча 2021 елның I кварталына торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 2020 елның 24 декабрендәге 852/пр номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2021 елга гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен чик күрсәткечләр билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен - 1 779 327 сум;

1.1.2. ике кешелек гаилә өчен – 2 264 598 сум;
1.1.3. өч кешелек гаилә өчен - 2 911 626 сум;

1.1.4. дүрт кешелек гаилә өчен – 3 882 168 сум;
1.1.5. биш кешелек гаилә өчен – 4 852 710 сум;
1.1.6. алты кешелек гаилә өчен – 5 823 252 сум;
1.1.7. җиде кешелек гаилә өчен – 6 793 794 сум.
1.2. һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 23 224,77 сум;

1.2.2. ике кешелек гаилә өчен – 14 779,40 сум;

1.2.3. өч кеше һәм аннан да күбрәк гаилә өчен – 12 457,78 сум.

2. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының Торак сәясәте бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән күрсәткечләрне гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗлар дип таныганда кулланырга.

3. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов